Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№3 (64) Декабрь, 2024 нче ел

*«Үз эшеңнең чын профессионалы булу – сикәлтәләр тулы юлны узу дигән сүз, болар барысы да безне көчлерәк итә һәм алга барырга стимул бирә».*

*Илсур Метшин, Казан Мэры*

Бу санда


| | |
|---|---|
| Мәктәп һәм гаилә - ышаныч җепләре | 2 |
| Максат куярга һәм тырышырга кирәк | 2 |
| Туган ягыма кыш килде | 3 |
| Инвалидлар декадасы | 3 |
| Солдатка хат | 3 |
| Яңа – 2025 елны каршылап | 4 |
| Йолдызнамә - 2025 (укучыларга) | 4 |


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Хөрмәтле гимназия коллективы һәм укучылар!




Менә декабрьнең соңгы көннәренә дә аяк бастык. Тиздән календарьдагы иң күркәм, иң эчкерсез, күңелле бәйрәм - Яңа ел җитә.

Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйм! Эшегездә, укуыгызда, тормышыгызда зур уңышлар юлдаш булсын! Елан елы укытучыларны укучыларының уңышлары белән сөендерсен.

Кадерле укучылар! Белемле һәм рухи яктан алга киткән кешеләр булу өчен сез бөтен көчегезне куярсыз дип ышанам.

***Гимназия директоры***
***Мирзаянов Азат Фәрит улы***

### Талантлы балаларның остазы - 2024




Казанның «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексында «Ел таланты - 2024» республика премиясе җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды.

Гимназиянең биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәһәметдиновна «Талантлы балалар һәм яшьләрнең педагоглары һәм остазлары» номинациясендә җиңү яулады.

Ләйсән Фәһәметдиновнаны чираттагы уңышлары белән котлыйбыз!


### Ел укытучысы



Районыбызда 10-12 нче декабрь көннәрендә "Ел укытучысы" Россиякүләм конкурсының муниципаль этабы үтте. Анда гимназиябез мөгаллимнәре Булатов Д.Д., Латыйпова И.В., Хәсәнова М.К. катнашты. Алар дәрес, осталык класслары күрсәттеләр, һөнәри компетенцияләр буенча сорауларга җавап бирделәр. Җиңүчеләр дә билгеле, башлангыч сыйныфлар укытучысы Ирина Владимировна лауреат исемен яулады.

Котлыйбыз! Җиңүләрегез дәвамлы булсын!

### Олимпиадалар укучыларны да, укытучыларны да сыный



Укытучы һәм укучыларның иҗади эшләргә сәләте, һичшиксез, олимпиада күрсәткечләрендә чагылыш таба. Елдан-ел аның биремнәре катлаулана бара.

Муниципаль этап нәтиҗәләре түбәндәгечә:

**37** - җиңүче;
**140** – призер.

## МӘКТӘП ҺӘМ ГАИЛӘ - ЫШАНЫЧ ҖЕПЛӘРЕ



"Мәктәп һәм гаилә - ышаныч җепләре" муниципаль проекты кысаларында, ел дәвамында, гимназиядә әти-әниләр белән кызыклы очрашулар үтте. Һәр сыйныф бу очрашуларны үзенчә, кызыклы итеп үткәрергә тырышты. Эшлекле иртәнге аш форматында үткәрелгән бу чараларда гаилә кыйммәтләре, хәзерге вакытта гаиләләрне борчыган сораулар каралды, бала шәхесен тәрбияләүдә әти-әнинең роле турында әңгәмәләр корылды. Әти-әниләрнең, әби-бабайларның тәпле киңәшләре тыңланды. Бала язмышында мәктәпнең тоткан урыны ассызыкланды.





## МАКСАТ КУЯРГА ҺӘМ ТЫРЫШЫРГА КИРӘК

**2024 ел узып бара. Һәркем үтеп баручы елга нәтиҗә ясый. Укытучыларыбыз нинди максатлар, уй-хыяллар белән каршылый 2025 елны? Шул турыда сөйләшеп алдык.**

Бездә кунакта гимназиянең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Ямалова Гөлнара Фердинанд кызы.

***1. Гөлнара Фердинандовна, балачакта кем булырга хыялландыгыз?***

Балачакта бик тә табиб буласым килә иде. Медицина белән кызыксынуым бүгенгәчә дәвам итә.

Ә бу юлдан китмәвемнең сәбәбе гади - химия фәне укытылмады (химия укытучысы булмау сәбәпле). Шуңа күрә, балаларга әйтер теләгем шундый: гимназия укытучылары – үз һөнәрләренең чын осталары, аларның кадерләрен белеп, тырышып укыгыз, барлык мөмкинлекләрне кулланып калырга тырышыгыз.

Укытучы һөнәрен сайлаганга да беркайчан да үкенгәнем булмады. Әлеге һөнәрне сайлауга үз укытучыларымның (бигрәк тә татар теле һәм әдәбияты укытучыбыз Мирзаянова Мәрзия Мирзанур кызының) шәхси үрнәкләре, киңәшләре йогынты ясады.

***2. Хыяллар тормышка ашсын өчен нәрсә эшләргә кирәк?***

Хыяллар тормышка ашсын өчен, авырлыклардан курыкмаска,беренче каршылыклардан, абынып егылулардан каушап калмаска, бары тик алга гына барырга кирәк. Тырышлык, тагын бер тапкыр тырышлык, тырыш булсаң бар хыялларың да чынга аша дип уйлыйм.

***3. Алтын балык тотсагыз, нинди өч теләк теләр идегез?***

- Үземә, гаиләмә, әти-әниемә, якыннарыма сәламәтлек, җан тынычлыгы, кайгы-хәсрәтсез тормыш;

- Илебезгә тынычлык, сугышның туктавын, сугыштагыларның исән-имин кайтуларын;

***Бездә кунак бар***



- Укытучыларның җәмгыятьтә абруй (дәрәҗә)ләре артуын һәм лаеклы хезмәт хакы алуларын сорар идем.

***4. Узып баручы ел нәрсәсе белән исегездә калды?***

Узган ел тормышымда зур үзгәрешләр елы булды дип әйтә алмыйм, минем күңелгә ел тотрыклы булуы белән якын булды. Минем өчен бу бик яхшы.

Гөлнара Фердинандовна җавапларыгыз, киңәшләрегез өчен бик зур рәхмәт.

***Сораштыруны үткәрде:***
***Замалова Зәринә***

## ТУГАН ЯГЫМА КЫШ КИЛДЕ

*Мөслим гимназиясенең 4 нче а сыйныфы укучылары иҗаты*



Кыш житте. Бар дөнья ап-ак булды. Без “мәш” килеп, кар көрибез. Уйныйбыз, шуабыз, кар атышабыз.

Кошларга кыш көне бик кыен. Аларга җимлекләр ясап элэбез.

Мин кышны яратам.

***Салихова Айгөл***

***

Менә кыш та житте. Җир йөзен ап-ак кар каплады. Агачларга, чыршыларга бәс кунды.

Балалар кар бабай ясыйлар, чанада шуалар. Суык битләрне чеметсә дә, курыкмыйбыз. Кыш көне бик рәхәт!

***Сәмигуллин Айгиз***

Менә көтеп алынган кыш килде. Бөтен яланнар, урманнар ак төскә керде. Куяннар соры туннарын акка алмаштырды. Агачларда күптән яфраклар коелып беткән, шәрәләнеп калганнар. Чыршы белән нарат кына яшел. Алар Яңа елны түземсезләнеп көтеп торалардыр кебек.

Анда-санда тукран тукылдап ала, агачтан корт чүпли. Төлке дус азык эзләп әрле-бирле йөри. Җил агачларның ботакларын селкетә.

Кышкы урманда сихри бер матурлык бар.

***Нәҗипов Азамат***

***

Алтын көз үтте, салкын кыш килде. Җир өстенә ап-ак юрган ябылды. Елга-күлләр шома боз белән капланды. Балалар чаңгы-чана шуарга чыктылар.

Туган ягыбызның кышы бигрәк матур!

***Идиятуллина Риана***

Менә кабат үзенең салкыннары, кар-бураннары белән кыш та җитте.

Бөтен дөнья аклыкка, сафлыкка төренде. Агачлар ак бәскә төренде, гүя ак шәлләрен ябындылар. Көннәр салкынайды. Елга-күлләр боз белән капланды. Көннәр кыскарды, төннәр озынайды. Кояш та сирәк кенә үзенең нурларын күрсәтеп ала.

Шулай да без кышны бик яратабыз.

***Газетдинова Камилла***

***

Аклыгын-сафлыгын, суыкларын, бураннарны тояп, туган ягыма кыш килде. Сиздерми генә килде бу гаҗәеп кыш. Күреп тә өлгермәдем, урамнарга, ишегалларына кар өемнәре тулды.

Өр-яңа, беркемнең дә аягы басмаган беренче кардан атлавы да - үзе бер могҗиза, үзе бер шатлык. Ә кар бөртекләре! Алар ак чәчәкләрдәй салмак кына биеп, җиргә урнашалар.

***Нуриева Динә***

## ИНВАЛИДЛАР ДЕКАДАСЫ

***“Авырлыкны җиңәр өчен көч кирәк, ә кешегә һәрчак җылы сүз кирәк”***





2024 нче елның 1-10 нчы декабрендә Россиядә Халыкара инвалидлар көненә багышланган Инвалидлар декадасы үткәрелде, ул 1992 нче елдан бирле ел саен 3 нче декабрьдә билгеләп үтелә.

Инвалидлар декадасы-кешеләргә игътибар, шәфкатьлелек, кайгыртучанлык һәм ярдәм кирәклеген һәркемгә искәртү ул.

Инвалидлар декадасы уңаеннан, гимназиядә ярминкәләр оештырылды. Ярминкәдә 1-11 нче сыйныф укучылары һәм аларның ата-аналары катнашты. Һәр сыйныф үзенең сату урынын зәвыклы бизәргә тырышкан. Укытучылар, укучылар һәм ата-аналар әлеге чараны әзерләү һәм оештыру өчен күп көч куйдылар. Биредән әйбер сатып алмыйча, тыныч кына үтеп китәрлек түгел иде. Ярминкә күтәренке кәеф, онытылмас тәэссоратлар бүләк итте. Хәйрия ярминкәсе бик яхшы һәм уңышлы узды. Ярминкәдән кергән акчалар инвалид балаларга тапшырылды.

Әти-әниләргә, сыйныф житәкчеләренә - ярминкәләрне оештыруда өлеше кергән һәркемгә зур рәхмәт!

## СОЛДАТКА ХАТ



Махсус хәрби операциядә хезмәт итүче абыйлар туган якларыннан һәрдаим җылы хәбәр көтәләр. Балалар тарафыннан язылган хатлар аларның күңелләренә аеруча җылылык өсти.

Гимназия укучылары да, һәрдаим, солдатларга ихлас теләкләр белән өчпочмаклы хатларын юллый. Яңа ел алдыннан, бәйрәм белән котлап хатлар язылды.

Аларда түбәндәге юллар бар: "Батырлыгыгыз һәм каһарманлыгыгыз өчен рәхмәт! Исән булыгыз! Сезне Көтәбез! Сезнең белән Горурланабыз!».

Күңел җылысы белән язылган өчпочмаклы хатлар хәрбиләргә гуманитар йөк белән бергә озатылачак.

## ЯҢА – 2025 ЕЛНЫ КАРШЫЛАП



*Җыр булып үрелеп күңелгә,*
*Кил безгә, Яңа ел, кил безгә!*

**Яңа елга кадәр эшләнергә тиешле эшләр**

1. Яңа ел чыршысын бизә.
2. Якыннарыңа бүләкләр әзерлә.
3. Каникулда карарга фильмнар, укырга китаплар зэерләп куй.
4. Кышку урманда фотосессия ясa.
5. 2025 нче елга максатларыңны яз.

## ЙОЛДЫЗНАМӘ - 2025 *(укучыларга)*



**Кучкар.** Быел мөстәкыйльлеккә өйрәнергә кирәк. Яңа идеяләрне тормышка ашыру өчен дә уңай ел. Сәламәтлегеңне ныгытырга спорт ярдәм итәр.

**Үгезбозау.** Чын дуслар табарсың. Башланган һәр яңа эшең зур һәм җитди әһәмияткә ия булыр. Үссүзле булуыңны укуга юнәлт. Яхшы билгеләр дә озак көттермәс.

**Игезәкләр.** Җитез, уңган булуың күп нәрсәләргә өлгерергә ярдәм итәр. Кызыклы шөгыльләр тап һәм һәр көнеңне файдалы уздырырга тырыш.

**Кысла.** Укуда ачышлар елы. Яңа сәләтләрең дә ачылачак. Музыка, бию, рәсем – үзеңә якын өлкәне сайлап ал. Ә бәлки шигырь яза башларсың?

**Арыслан.** Әти-әниеңнән серләреңне яшермә. Аларның киңәшләрен тыңласаң, эшләрең уң булыр. Дусларың белән күбрәк аралашырга тырыш.

**Кыз.** Фантазияң ташып торыр. Белемеңне, көчеңне сынау елы. Төрле уеннар, бәйгеләрдә җиңү килер. Тормыш һәм уку кагыйдәләрен бердәй тигез бел.

**Үлчәү.** Күп белергә, яхшы укырга омтыл. Игътибарлылыгыңны арттыр. Алган белемнәрең киләчәгең өчен кирәкле булыр. Игелекле эшләр турында да онытма.

**Чаян.** Энергияң ташып торачак. Шулай да сабырлык һәм тынычлык турында да онытма. Күбрәк китаплар, газета-журналлар укы.

**Укчы.** Гаиләң белән дуслыкны ныгыту, якын кешеләрең белән күбрәк аралашу елы. Кунакка күп йөрерсең. Үзеңдә дусларыңны чакырырга онытма.

**Кәҗәмөгез.** Холкыңның төрле яктан ачылуын көт. Тиктормас та, шул ук вакытта күп белергә омтылучан да син. Тарихи урыннар һәм табигатькә соклану яхшы кәеф бүләк итәр.

**Сукояр.** Мөстәкыйль бул һәм үз уйларыңны, хыялларыңны тормышка ашырырга тырыш. Яңа һөнәрләр хакында күбрәк укы.

**Балык.** Яшьтәшләрең белән аралашып, дуслар табу елы. Өй эшләрендә әти-әниеңә ярдәм итәргә тырыш, аларга игътибарыңны һәм җылы мөнәсәбәтеңне кызганма.

ТЫЛСЫМ+
Декабрь, 2024 нче ел
№3 (64)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100